**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы**

**КАРАРЫ**

**2017 елның 13 мартта** **№ 85**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару һәм индивидуаль торак төзелеше өчен гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләренең чик күләмнәрен билгеләү турында

Җирләрдән оптималь файдалану, гражданнарны җир кишәрлекләре белән тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкны үстерү максатларында, шулай ук гамәлдәге законнарга, Россия Федерациясе Җир кодексына, Татарстан Республикасы Җир кодексына, «шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 07.07.2003 ел, № 112-ФЗ Федераль законга таянып, Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Кама Тамагы муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару һәм индивидуаль торак төзелеше өчен гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләренең чик күләмнәрен билгеләү турында» 2008 елның 15 февралендәге 161 номерлы карары (Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2010 елның 29 декабрендәге 41 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып) үз көчен югалткан дип танырга.

2. Дәүләт яисә муниципаль милектә булган җирләрдән гражданнарга арендага яки милеккә бирелә торган җир кишәрлекләренең чик (максималь һәм минималь) күләмнәрен билгеләргә:

а) шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен:

- торак пункт чикләрендә (йорт яны җир участогы) 0,06 гектардан 0,15 гектарга кадәр.,

- торак пункт чиге артында (кыр җир участогы) 0,06 гектардан 1,0 гектарга кадәр;

б) индивидуаль торак төзелеше өчен 0,06 гектардан 0,15 гектарга кадәр.

3. Әлеге карарның 2 пунктында каралган җир кишәрлекләренең иң чик (максималь һәм минималь) күләме гражданнарга әлеге карар үз көченә рәсми кергәннән соң бирелә торган җир кишәрлекләренә (Яңа бүлеп бирелә торган җир кишәрлекләренә) кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның 2 пунктында каралган җир кишәрлекләренең иң чик (максималь һәм минималь) күләме гражданнарга әлеге карар кабул ителгәнче арендага бирелгән һәм гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә алар сатып алган җир кишәрлекләренә кагылмый дип билгеләргә.

5. Карар «Волжские зори» («Идел таңнары») район газетасында рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,

муниципаль район Советы рәисе П. Н. Лоханов